Нигъмәтуллина, З. Лиманың чәчәкле мохите / З. Нигъмәтуллина // Сөембикә. - 2023. - №9. - С. 64-65.








# ЛИМАНЫҢ ЧӘЧӘКЛЕ МОХИТЕ

Чаллының талантлы рәссамы, педагог Лима Рәфикъ кызы Букина 1967 елның 26 гыйнварында Башкортстанның Борай районы Зур Бадрак авылында туа. 1969 елдан алып әти-әнисе белан шушы республиканың Кызыл Кама районы Николо-Березовка бистәсендә яши. Нефтекамскидагы балалар сынлы сәнгать мәктәбендә белем ала. Аннары 1984 елда Алабуга дәүләт педагогика институтының Чаллы филиалына укырга керә. Укуын тәмамлагач та Лима Рәфикъ кызы Чаллы дәүләт педагогика институтының «Сынлы сәнгать һәм сызым укыту методикасы» кафедрасында эшли башлый, студентларга рәсем, сынлы һәм гамәли сәнгать, махсус методикаларны укыта, курс һәм диплом эшләре житәкчесе була. Лима ханым Кама сәнгать һәм дизайн институтында рәсем сәнгатең, үзенчәлекле текстиль, декоратив-гамәли стильләштерү кебек дәресләрне алып бара. 2008 елдан шушы институтның проректоры вазыйфаларын да башкара.
2007 елда Лима «Дизайнерлар берлеге» халыкара җәмәгать ассоциациясенә кабул ителә. Ул - Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы. Бихисап күргәзмәләрдә, арт-проектларда, пленэрларда катнашып килә. Иҗаты күпләрдә якты акварель әсәрләре белән кызыксыну уята. Ул сәнгатьнең шушы юнәлешенә башкаларны да төшендерергә омтыла, узе яраткан акварель жанры буенча осталык дәресләре дә үткәрә.
2012 һәм 2022 елларда Россия Сынлы сәнгать академиясе Букинага үз Рәхмәт хатларын тапшырган. Соңгы Рәхмәт хаты - Болгарда ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган Бөтенроссия пленэрын оештырганы өчен. Аньң шушы пленэр вакытында ясаган бер хезмәте хәзерге көндә «Казан Кремле музей-тыюлыгы»нда саклана.
Милли чараларда актив катнашканы өчен - Бөтендөнья татар конгрессыньң, «Гаилә» паркында скульптура композициясе куелуга булышлык иткәне өчен - Түбән Кама хакимиятенең Рәхмәт хатлары шулай ук иҗатына зур бәя.
Кызы Рузаннаның иҗаты да куандырып тора. «Кызым Кама сәнгать һәм дизайн институтыньң костюм дизайны бүлеген тәмамлады, мода өлкәсе белгече булып китте, - ди Лима ханым. - Бүгенге көндә ул хөрлек рухын, этникадагы матур элементларны уз эченә алган бохо стилендәге кием коллекцияләрен һәм премиум-класс кием-салымнарын иҗат итә. Минем инде ике оныгым да бар, иншаллаһ. Ева белән Летиция дә үсеп җиткәч, дизайн йә рәссамлык белән бәйле һөнәрләрдә булырлар дип өметләнәм».


Рәссам-акварелист үз әсәрләрен ясау өчен күбесенчә юеш кәгазьләр сайлап ала, шуңа күрә алардагы сурәтләр дә күңелләргә якын һәм ямьле килеп чыга. Иҗатында - кояшлы мохиттә сурәтләнгән сусыл җиләк-җимешләр, төрледән-төрле чәчәкләр... Рәссам аларны иҗат иткәндә лессировка - күп катлам ясау ысулын оста куллана һәм бу ысул акварель буяулы рәсемнәрне киндергә ясалган картиналарга да якынайта төшә, чөнки төсләр дә җетерәк, әллә каян җәлеп итеп, «кычкырып» торалар, шул ук вакытта җиңеллекләрен дә югалтмыйлар! Аның «а prima» алымы белән иҗат ителгән хезмәтләре дә бинидһая күп, ә мондый Лима рәсемнәрдә хисләр муллыгы - һәрчак артыгы белән, кабат кучереп ясап та булмый үзләрен, чөнки алар - берничә мизгел эчендә ясалган сурәтләр!


Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА













ЛИМА БУКИНА